# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Актаныш районы буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Актаныш районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 120-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Актаныш районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать
судьяларының суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Актаныш муниципаль районының Аеш, Аккүз, Актаныш, Кәзкәй, Яңа Әлем, Иске Байсар, Иске Богады, Теләкәй, Чишмә һәм Чуракай авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Актаныш муниципаль районының Актанышбаш, Әтәс, Югары Яхшый, Киров, Күҗәкә, Мәсәде, Яңа Кормаш, Пучы, Иске Айман, Иске Кормаш, Иске Сәфәр, Такталачык, Татар Суыксуы, Татар Ямалысы, Түке, Уразай, Усы һәм Чалманарат авыл җирлекләре.